**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 февраль № 119

г. Казань

Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау» 1994 ел, 21 декабрь, ФЗ-68 нче, «Дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны һәм муниципаль тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр хокукларын яклау турында» 2008 ел, 26 декабрь, ФЗ-294 нче федераль законнар, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-62 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\119.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 26 февраль, 119 нчы карары белән расланды

**Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе**

1. Әлеге Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе (алга таба – Тәртип) «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау» 1994 ел, 21 декабрь, ФЗ-68 нче, «Дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны һәм муниципаль тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр хокукларын яклау турында» 2008 ел, 26 декабрь, ФЗ-294 нче федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге турында» 2015 ел, 24 декабрь, 1418 нче карары, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-62 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген (алга таба – төбәк дәүләт күзәтчелеге) оештыру һәм гамәлгә ашыруны регламентлаштыра.

2. Төбәк дәүләт күзәтчелеге җирле үзидарә органнары, юридик затлар, аларның җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлар (алга таба – юридик затлар), индивидуаль эшмәкәрләр, аларның вәкаләтле вәкилләре (алга таба – индивидуаль эшмәкәрләр) һәм гражданнар тарафыннан «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау» 1994 ел, 21 декабрь, ФЗ-68 нче Федераль закон белән билгеләнгән, аның нигезендә башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары белән кабул ителә торган, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-62 нче Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән таләпләрне (алга таба – мәҗбүри таләпләр) үтәүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасына йөкләнгән бурычлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Төбәк дәүләт күзәтчелеге Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Төбәк дәүләт күзәтчелеге «Дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны һәм муниципаль тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм

индивидуаль эшмәкәрләр хокукларын яклау турында» 2008 ел, 26 декабрь, ФЗ-294 нче Федераль закон нигезендә планлаштырылган һәм планнан тыш, документлар буенча һәм күчмә тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

5. Вәкаләтле орган халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы органнар, шулай ук башка төрдәге дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар белән үзара хезмәттәшлек итә.

6. Вәкаләтле органның төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары (алга таба – вазыйфаи затлар) исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

7. Вазыйфаи затлар үз вәкаләтләре чикләрендә Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

а) җирле үзидарә органнары, юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр һәм гражданнар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәүгә тикшерүләр оештыру һәм үткәрүне;

б) федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар белән мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлекне;

в) административ хокук бозулар турындагы эшләрне алып баруны;

г) мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү мәсьәләләре буенча оешмалар һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен һәм шикаятьләрен карап тикшерүне.

8. Вазыйфаи затлар түбәндәге хокукларга ия:

а) тоткарлыксыз, хезмәт таныклыгын һәм билгеләнгән тәртиптә расланган тикшерү билгеләү турында вәкаләтле орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) боерыгы яки әмере күчермәсен күрсәтеп, аларга карата тикшерү үткәрелә торган юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр эшчәнлекләрен гамәлгә ашырганда файдаланыла торган территорияләр, биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм урыннарга бару, шулай ук тикшерү үткәрү;

б) аларга карата тикшерү үткәрелә торган җирле үзидарә органнары, юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләрдән мәҗбүри таләпләрне үтәүгә тикшерүләр оештыру һәм үткәрү өчен кирәкле документлар һәм мәгълүмат соратып алу, әгәр әлеге документлар һәм мәгълүмат тикшерүгә кагылышлы булса;

в) мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирү.

9. Югары вазыйфалардагы затларның күрсәтмәләре һәм боерыклары түбәнрәк вазыйфалардагы затлар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш.

10. Вазыйфаи затлар үзләренә йөкләнгән бурычларны үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тота.

11. Вазыйфаи затларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата Россия Федерациясе законнары нигезендә административ тәртиптә һәм (яки) суд тәртибендә шикаять бирелә ала.

---